**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **11.12.2019**

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы Тымытык авыл жирлеге
составына керүче Әгер авылында
2020 елда гражданнарның үзара салымын
кертү турында

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Әгер авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Тымытык авыл җирлеге Әгер торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар өчен 200 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- Әгер авылында М.Җәлил ур., Совет ур., Тукай ур., буенча вак таш белән юлларның чокырларын ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Әгер авылында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампаларны урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Әгер авылы территориясендә җыештыру, көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарларны вакытлыча җыю, чистарту;
- Әгер авылында «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәм чараларын үткәрү өчен бүләк, сувенир продукциясе сатып алу;
- Әгер авылында спорт чараларын үткәрү өчен бүләк, сувенир продукциясе сатып алу;
- Әгер авылларындагы юлларны кардан чистарту;
- Әгер авылларында җәйге чорда территорияләрне чабу;
- Әгер авылларында коры агачлар, куаклар киселде;
- Әгер авылларында урам исемнәре язылган күрсәткечләр сатып алу (әзерләү) һәм урнаштыру (килешү буенча эш өчен түләү).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль

берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Тымытык авылы, Тельман урамы, 62Б нчы йорт, Әгер авылы, Совет урамы, 27 нче йорт.

Гражданнар жыенында рәислек итүче,
Тымытык авыл җирлеге Башлыгы Э.Х. Гыйләҗева